Муниципальное автономное образовательное учреждение «Детский сад №20» общеразвивающего вида «Мозаика» Чистопольского муниципального района Республики Татарстан

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Гомуми үсеш төрендәге 20 нче номерлы“Мозаика” балалар бакчасы” муниципаль үзидарәле мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе

**Утверждена и введена** в действие
приказом заведующего МАДОУ «Детский сад №20»
от 31.08.2022 года № 88
_______________Ж.Е. Зиновьева

# Рабочая образовательная программа
младшей группы (3-4 лет) «Гномики»
на 2022-2023 учебный год

2022-2023 нче уку елына
II кечкенәләр “Гномиклар” (3-4 яшь) төркемендә
белем бирү эш программасы

**Рассмотрена и принята**
на заседании педагогического совета
протоколом № 1 от 31.08.2022 года

Тәрбияче: Камалова Г.Г.
Багманова Е.В.

Чистополь , 2022 год

## Эчтәлек

**I.Максатчан бүлек**


l.1.Программаны тормышка ашыру өчен максаты һәм бурычлары ....................................3
I.2.Программаны тормышка ашыруда мөһим характеристикалар. .....................................3
1.3.3-4 яшьлек балаларның психик үсешенең яшь үзенчәлекләре.....................................4
1.4. .Программа материалын үзләштерүдә көтелгән нәтиҗә..........................................5
I.5. Төркем эшчәнлегенең төп юнәлеше......................................................................6


## II. Эчтәлек бүлеге


II.1. Комплекслы - тематик план...............................................................................6
II.2.Гаилә белән үзара аралашу....................................................................................7


## III.Оештыру бүлеге


III.1.Материаль-техник тулыландыру....................................................................... .....11
III.2.Методик кулланма..............................................................................................12
III.3.Үстерешле предметлы тирәлекнең үзенчәлекләре.......................................................13
III.4. Көндәлек режим.............................................................................................14
III.5. Белем бирү эшчәнлеге челтәре...............................................................................15
III.6.Сәламәтләндерү чаралары.................................................................................... .15
III.7.Традицион вакыйгалар, бәйрәмнәр, чаралар.....................................................................16

## I.Максатчан бүлек

### I.1.Программаны тормышка ашыру өчен максаты һәм бурычлары.

***Максат:***- һәр баланың сәламәтлеге, эмоциональ иминлеге һәм үз вакытында һәр яктан үсеш алуы турында кайгырту;

- балаларны аралашучан, игелекле, кызыксынучан, инициативалы, мөстәкыйльлеккә һәм иҗатка омтылучан итеп үстерү максатыннан чыгып, төркемдә кешелеклелек һәм мәрхәмәтлелек атмосферасы тудыру;
- балалар эшчәнлеген төрле төрләрен киң куллану, укыту һәм тәрбия процессының нәтиҗәлелеген күтәрү максатыннан аларны интегральләштерү;
- тәрбия һәм белем бирү процессын иҗади оештыру;
- балаларның мөмкин булганча төрле эшчәнлекләрен файдалану, белем бирү процессын нәтиҗәлерәк итү максатында аларны берләштерү;
- мәктәпкәчә тәрбия һәм белем бирү оешмасы һәм гаилә шартларында бала тәрбиясенә якын килүгә юнәлеш бирү;
- гаиләнең балалар бакчасы төркемнәре һәм мәктәпкәчә оешманың тормышында катнашуын тәэмин итү;
- балалар бакчасы эшендә мәктәпкәчә яшьтәге балага артык акыл һәм физик эш йөкләмәү максатыннан саклау;
- региональ якын килүне гамәлгә ашыру.

***Бурычлар*:**-балаларның сәламәтлеген ныгытуга комплекслы килү, аларның психик-эмоциональ иминлеген тәэмин итү;

- әйләнә-тирә дөньяга, туган гаиләсенә, туган йортына, туган җирлегенә, Туган иленә, төрле милләт кешеләренә уңай мөнәсәбәт тәрбияләү;
- балаларның физик һәм психик сәламәтлеген саклау һәм ныгыту;
- гаиләнең һәм җәмгыятьнең традицион рухи-әхлакый кыйммәтләре нигезендә гаиләнең һәм балалар бакчасының тәрбияви-сәламәтлек ресурсларын берләштерү;
- гаилә белән үзара партнерлык мөнәсәбәте урнаштыру, психологик һәм педагогик ярдәм күрсәтү, белем һәм тәрбия бирүдә ата-аналарның компетентлылыгын күтәрү;
- психолог ярдәме белән балаларга белем бирү эшчәнлегендә барлыкка килгән кимчелекләрне бетерү өстендә эшләү.
- белем бирү һәм тәрбия эчтәлеген, шартларын, технологияләрен модернизацияләү юлы белән белем бирү процессын яңарту.

### 1.2. 3-4 яшьлек балаларның психик үсешенең яшь үзенчәлекләре

Өченче яшьтә балалар мөстәкыйль була башлыйлар. Предмедлы эшчәнлек, бала белән өлкәннәрнең ситуатив – эшлекле аралашулары үсә бара, кабул итү эшчәнлекләре, сөйләм, үз-үзләрен ирекле тотуның башлангыч формалары, уеннар, күрсәтмәле-тәэсирле фикер йөртүләре камилләшә.

Предметлы эшчәнлек үсеше төрле предметлар белән культурлы эш итү ысулларын үзләштерүгә бәйле.Мөнәсәбәттәш һәм кораллы эш-гамәлләр үсә.

Охшарга тырышу обьекты сыйфатында һәм шулай ук балаларның үз активлыгын да үстерүче үрнәк итеп олылар тәкъдим иткән модель нигезендә, кораллы эш-гамәлләр табигый активлыкны, белем һәм күнекмәләр ярдәмендә барлыкка килүче (культуралы) активлыкка үзгәртеп,баланың ирекле тәртибен үстерәләр.

Олылар белән уртак предмет эшчәнлеге барышында сөйләмне аңлау үсә. Сүз ситуациядән аерыла һәм мөстәкыйль мәгънә ала бара. Балалар үзләрен әйләндереп алган предмет исемнәрен үзләштерүләрен дәвам итәләр, олыларның гади сүз белән белдергән үтенечләрен үтәргә өйрәнәләр. Бала аңлый торган сүзләр саны шактый арта. Бала олыларның күрсәтмәләрен генә түгел,ә аларның хикәяләүләрен дә аңлый башлый. Моңа бәйле рәвештә олыларның мөрәҗәгате нигезендә балаларның тәртипләрен көйләү камилләшә.

Балаларның актив сөйләме интенсив үсә. 4 яшькә алар төп грамматик структураларны үзләштерәләр, гади җөмләләр төзергә тырышалар, өлкәннәр белән сөйләшкәндә барлык сүз төркемнәрен дә диярлек кулланалар. Актив сүзлек якынча 1500-1900 сүзгә җитә. 4 яшь туларак сөйләм балаларның яшьтәшләре белән аралашу чарасына әйләнә. Бу яшьтә балаларда уен, рәсем ясау, конструкцияләү кебек яңа эшчәнлек төрләре формалаша.

Уен процессуаль характер ала, анда иң мөһиме –эш хәрәкәтләр. Балалар чынбарлыкка якынлаштырылган уен предметлары белән уйныйлар. 4 нче яшьнең урталарында бер предметны икенчесе белән алыштырып уйнау үнекмәләре барлыкка килә.

Сурәтләү эшчәнлеге барлыкка килү баланың ниндидер предметны сүрәтләргә теләгән белдерергә сәләтле булуы белән аңлатыла. Гадәттә бу кешене "башаяк" формасында (әйләнә һәм аннан китүче сызыклар) сүрәтләү.

4нче яшьтә күрү һәм ишетү сәләте камилләшә. Бу балаларга кайбер биремнәрне хатасыз үтәргә мөмкинлек бирә: 3-4 предметны формасы, зурлыгы һәм төсе буенча сайлап алу, көйләрне аеру, җырлау.

Ишетеп зиһенгә алу сәләте, бигрәктә фонематик ишетү камилләшә. 4 яшькә балалар туган телнең барлык авазларын беләләр, тик аларны бик нык бозып әйтәләр.

Күрсәтмәле тәэсирле форма фикерләүнең төп формасы булып тора. Аның үзенчәлеге шунда: бала тормышында килеп чыккан проблемалы ситуацияләр предметлар белән реаль эшчәнлек ярдәмендә хәл ителәләр.

Бу яшьтәге балаларга уй-фикерләрне аңлап бетермичә әйтү, импульсивлык, хисләр һәм теләкләренең ситуацияләрдән бәйле булуы характерлы. Балалар яшьтәшләренең эмоциональ хәләтенә бик җиңел биреләләр.Бу чорда балада иректе тәртип формалаша башлый. Ул кораллы эш гамәлләр һәм сөйләм үсеше белән аңлатыла. Балаларда горурлык һәм оялу хисләре барлыкка килә, исем һәм җенси тәңгәллек белән бәйләнешле үзаң элементлары формалаша башлый.

Иң кече яшьтәгеләр чоры 4 яшьлекләр кризисы белән тәмамлана. Бала үзенең олылардан аерылып торучы аерым кеше икәнлеген аңлый башлый. Анда Мин образы формалаша.

Кризис күп кенә тискәре күренешләргә сәбәпче була: негативлык, кирелек,еш кына өлкәннәр белән мөнәсәбәтләрнең бозылуы һ.б. Кризис берничә айдан 2 елга кадәр сузылырга мөмкин.

### I.3.Программа материалын үзләштерүдә көтелгән нәтиҗә.

-Бала эшчәнлек вакытларында, аралашу вакытында, танып белүдә, рәсем ясаганда,әвәләү вакытында,конструкцияләүдә теләп катнаша. Үзенең инициативасын күрсәтә һәм мөстәкыйль эшитәргә тырыша.

-Бала яшьтәшләре һәм өлкәннәр белән хезмәттәшлек итә, уртак уеннарында катнаша; башкаларның мәнфәгатьләрен һәм хисләр исәпкә алып үзара килешеп эш итә, аларның уңышларынана куану һәм кайгыларын уртаклашу хисләрен белдерә.

-Бала үзенең тәэсирле хисләрен төрле ысуллар аркылы күрсәтә белә, тискәре хисләрен тыеп тора; якыннарының , дусларының һәм әйләнә-тирәдәгеләрнең эмоциональ хәленә кереп, ярдәм итәргә әзер , хикәядәге геройларның, әкият персонажларының хәленә кереп, алар өчен борчыла; хисләр белән сугарылган сәнгать әсәрләренә, рәсем сәнгатенә, музыкага, табигать матурлыгына соклана һәм ләззәтләнә; хайваннар һәм үсемлекләр дөньясын кайгырта.

-Бала кызыксынучанлык күрсәтә, табигать күренешләрен һәм кешеләрнең башкарган гамәлләрен күзәтергә һәм аңлатырга омтыла.Табигатьтәге үзгәрешләрне күрә һәм әйтә белә:яңгыр,кар ява... Табигать матурлыгына соклана белә, хайваннар һәм үсемлекләр дөньясын кайгырта.

-Бала яше буенча хәрәкәтле, дидактик, с.рольле, өстәл уеннарын белә. Баланың эре һәм вак моторикасы үсеш алган; ул хәрәкәтчән, чыдам, төп хәрәкәтләрне үзләштергән, алар белән идарә итә һәм үзен контрольдә тота. Хәрәкәтле уеннарда теләп катнаша.

-Бала ихтыяр көченә ия, өлкәннәр һәм яшьтәшләре белән аралашканда, эшчәнлек барышында, үз-үзеңне тоту нормаларын һәм кагыйдәләрен һәм шәхси гигиена кагыйдәләрен үти.Көнкүреш әйберләреннән (кашык, тарак , карандаш һ. б.) белән файдалана белә.

- Әдәплелек кагыйдәләрен үти (мөстәкыйль рәвештә яки сораганда "рәхмәт", "исәнмесез", "сау бул", "тыныч йокы" сүзләрен (гаиләдә, төркемдә) әйтә; үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен балалар бакчасында да ,өйдә дә, урамда да үтәргә тырыша .

-Тәрбияченең сорауларын аңлый һәм җавап бирергә тырыша,уенчыкларның һәм тирә-юньдәге әйберләрнең исемнәрен белә.Шигырьләргә,җырларга,әкиятләргә карата кызыксынучанлык күрсәтә.Театральләштерелгән,курчак театры һәм сюжетлы уеннарында катнашырга тырыша.

### І.4. Төркем эшчәнлегенең төп юнәлеше

Төркемнең эшчәнлеге төп гомумбелем бирү Программасының үтәлешенә юнәлгән һәм түбәндәге документларга нигезләнә:

-"Закон об образовании в Российской Федерации" (Принят 29 декабря 2012года № 273-ФЗ);

-Постановление Главного государственного санитарного врача РФ СП 2.4.3648-20 "Санитарно-эпидемиологические требования к организациям воспитания, обучения, отдыха и оздоровления детей и молодежи» от 28 сентября 2020 года №28 ;

-ПриказМинобразования Российской Федерации "Об утверждении Федерального государственного образовательного стандарта дошкольного образования" от 17.10.2013 № 1155; -"Закон РТ № 44 от 28.07.2004г. "О государственных языках РТ и других языках в РТ".

Төркемдә белем бирү эшчәнлегенең эчтәлеге түбәндәге программаларга яраклаштырып төзелгән:

- Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү программасы "От рожения до школы»( Н.Е.Веракса, Т.С.Комаровой, М.А.Васильевой редакциясе астында, Москва «Мозаика-Синтез», 2010;

- "Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү программасы" К.В.Закирова, Р.А.Борһанова, Г.Ә.Галиева, З.Г.Ибраһимова.-Казан: Татар.кит.нәшер.,2010.

## ІІ. Эчтәлек бүлеге

### *ІІ.1. Комплекслы - тематик план*

| Тема | Эшчәнлек эчтәлеге | Үткәрү вакыты | Йомгаклау чарасы |
|---|---|---|---|
| Балалар бакчасы | 1.Балалар, әти –әниләре белән танышу.<br>2.Әти –әниләрне балалар бакчасының эшләү режимы белән таныштыру.<br>3.Балаларны балалар бакчасы белән (төркем, шәхси шкафлары, йокы бүлмәсе, уенчыклар) таныштыру.<br>4."Баланы балалар бакчасына әзерләү" әти-әниләр белән әңгәмә." | сентябрь 1-4атнасы | |
| Табигатьтә көз. | 1."Көз килде" әңгәмә<br>2. "Алтын көз" темасына рәсемнәр ясау(әти-әниләр белән берлектә).<br>3. "Яшелчәләр өлгерде" әвәләү. Җиләк-җимеш кибете | октябрь 1-4атнасы | Көзге уңыш" бәйрәме (әти-әниләр белән берлектә) Балалар иҗаты күргәзмәсе. |
| Мин — дөньяның бер кешесе | 1."Минем гаиләм" әңгәмә<br>2."Әби-бабай, дәү әти- дәү әни" әңгәмә | ноябрь 1-2 атна- | Мин бәхетле әби бабам белән" (әти-әниләр белән берлектә) фотоколлаж. |
| Минем өем,минем гаиләм " | 1." Без Татарстанда яшибез "әңгәмә.<br>2. Ата-аналарга музейларга ял көннәрендә экскурсия ясарга тәкъдим итү.<br>4. Төрле һөнәрләр белән таныштыру рәсемнәр карау. | ноябрь 3-4 атна | "Әниләр иң кадерле кешеләр" фотоколлаж. |
| Яңа ел | 1. "Яңа ел "турында шигырьләр.<br>2. "Яңа ел" турында җырлар өйрәтү. | декабрь | "Яңа ел бәйрәме" кичәсе. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 3. ” Яңа ел” уенчыклары күргәзмәсе (әти-әниләр белән берлектә).<br>5 . Участокта әти-әниләр белән тау ясау.<br>6. “Иң гузәл төркем” конкурсында катнашу.<br>7.“ Серле кар бөртекләре” (әти-әниләр белән берлектә эш). | | Чыршы, бүлмә бизәү. Уенчыклар ясау. |
| Кыш | 1. “Кар патшасы” әвәләү<br>2. Кышкы табигатькә экскурсия, җимлекләр элү. | 2-4 атна гыйнвар | “Туган ягымда кыш” күргәзмә. Чыршы белән саубуллашу |
| Юл йөрү кагыйдәләре кирәк безгә һәр көнне | 1. Юл йөрү билгеләре белән таныштыру.<br>2 Юл йөрү кагыйдәләре буенча әкиятләр уйлап чыгару<br>3. Юл йөрү кагыйдәләре буенча рәсем ясау (әти-әниләр белән берлектә). | 1-2 атна февраль | Юл йөрү кагыйдәләре кирәк безгә һәр көнне |
| Әтиләр һәм әниләр, бабайлар һәм әбиләр | 1 Ватанны саклаучылар көненә багышланган рәсемнәр карау.<br>2.. Әтиләргә бүләк.<br>3. 8март – халыкара хатын кызлар көне турында әңгәмә<br>4. Әниләргә бүләк. | 3-4 атна февраль-1-2 март | Әтиләр, әниләр бәйрәменә Күмәк эш: «Язгы букет».. |
| Халык иҗаты | 1. Халык иҗат иткән уенчыклар, уеннар белән танышу<br>2. Халык әкиятләре белән танышу.<br>3. Бармак уеннары. | 3-4 март | Халык уеннарын үткәрү. |
| Табигатьтә яз. | 1. Яз турында әңгәмә<br>2. “Туган ягыма яз килде” рәсемнәре карау<br>3. Язга багышланган җырлар. | 1-2 атна-апрель | Яз бәйрәме |
| Габдулла Тукайның әкият дөньясы | 1. Габдулла Тукай белән таныштыру.<br>2. Г. Тукайның әкиятләре белән таныштыру | Апрель 3-4 - атна | Тукай әсәрләренә сәяхәт. Рәсем конкурсы кул эшләнмәләре күргәзмәсе. Әти әниләр белән |
| Җәй | 1.Кыргый хайваннарның рәсемен карау<br>2.Йорт хайваннарның рәсемен карау<br>3.Үсемлекләр рәсемен карау | Май | Әти- әниләр берлектә бакча мәйданчыгын бизәү. |
| | Җәй айларында балалар бакчасы каникуляр режимда эшли. | Июнь-август | |

### *II.2.Гаилә белән үзара аралашу*

Хәзерге фән һәм практика баланың шәхесен формалаштыруда гаиләнең уникаль роль уйнавын исбат итә. Беренче социальләшү гаиләдә башлана, баланың дөньяга, үзенә, башка кешеләргә карашы, мөнәсәбәте формалаша. Ата-аналарның кайгыртучанлыгы балада аның үз-үзенә ышанычын тудыра, башка кешеләр белән түземлек, үзара хөрмәт принциплары нигезендә үзара мәнәсәбәткә керергә әзер торырга ярдәм итә. Ата-ананың тәрбия һәм белем бирү эшчәнлегендә катнашу мөмкинлеге булу бик зур әһәмияткә ия. Хәзерге заман балалар бакчасы ата-аналарга психологик һәм педагогик ярдәм күрсәтүче учреждение буларак та хезмәт итә. Шул ук вакытта гаилә дә үзара хезмәттәшлек итәр өчен педагогларны өзлексез үсешкә рухландыра. Түбәндәге *бурычларны* үтәмичә, максатка ирешү мөмкин түгел:

-гаилә белән партнерлык мөнәсәбәте урнаштыру;

-бакчада ата-анага бала тормышында катнашу өчен шартлар тудыру;

-бала тәрбияләүдә ата-аналарга психологик ярдәм күрсәтү;

-гаиләләр белән үзара аралашуда педагогик компетентлыкны өзлексез күтәрү.

Гаилә белән үзара бәйләнеш принциплары.

1.Психологик уңайлык (комфорт) принципы – ата-аналар белән аралашуда җылы атмосфера булдыру, һәр гаиләнең ихтыяҗын, социаль-психологик характеристикасын исәпкә алу. Ата-ана белән үзара ышанулы мөнәсәбәт ул – хөрмәт, диалогка омтылу, игътибарлылык, ихласлылык. Балага һәм аның якыннарына карата тәрбиячинең игелеклелеге һәм ачыклыгы ата-ана ягыннан уңай кабул ителә. Ата - аналарның бакчада балалары шат булса, алар тәрбиячеләргә сораулар белән мөрәҗәгать итәләр. Ата-аналарның бала өчен балалар бакчасының уңайлы, куркынычсыз, файдалы булуын күрү генә түгел, ә балаларның үсешен күрүләре дә әһәмияткә ия. Тәрбиячинең баланың яшь үзенчәлеген, психологиясен, үсеш кризисын белүе, ата-ананы тынычлындырып, кирәкле сүзләр таба белүе, алар белән ягымлы мөгаләмәдәге әңгәмәдәшче булуы мөһим.

2.Эшчәнлек принцибы. Белем һәм тәрбия бирү процессында балалар бакчасы һәм ата-аналар арасындагы бәйләнештигез хокуклы партнерлар сыйфатына корылган. Партнерлык процессы катлаулы: танышу, стереотипларның җимерелүе һәм үзара аңлашу урнашу, бала тәрбияләүдә бер үк максатны күздә тоту. Педагогның һәм балалар бакчасының позитив имиджы булуы мөһим.

3.Бербөтенлек принцибы – тәрбия һәм белем бирүдә гаилә һәм җәмгыять институтларының аерылгысыз бербөтен булуына нигезләнгән. Әлеге принцип бала тәрбияләүдә гаилә белән балалар бакчасының эш стратегиясен билгели. Җәмгыяти тәрбиянең нигезе ул - балага социаль таләпләр системасы кую. Ата-аналарның тәрбияви тәэсире булып, балага карата мәхәббәт, аны куркынычсызлык белән тәэмин итү, аны ничек бар шулай кабул итү тора.

4.Минимакс принцибы – һәр гаиләгә дифференциаль якын килү, ата-аналар белән эчтәлекле, тактлы аралашу. Ата-аналар белән танышкач, педагог һәр гаиләнең үзенчәлеген ачыклый, аларның активлыгын күтәрү өчен планлы рәвештә шартлар тудыра.

5.Вариативлык принцибы – ата-аналарга тәрбия һәм белем бирү процессына кушылу һәм аралашуның формаларын тәкъдим итү: традицион һәм традицион булмаган, шәхси һәм төркемләп, дистанцион һәм кара-каршы аралашу.

6.Өзлексезлек принцибы өйдә һәм балалар бакчасында тәрбия бирүнең өзлексез баруын күз алдында тота.

7.Иҗадилык принцибы – тәрбия һәм белем бирү процессында барысына да иҗадилык күрсәтергә мөмкинлек ачу.

*Ата-аналар белән үзара бәйләнеш формалары*.

1.Мәгълүмати чаралар – телдән журнал, реклама буклеты; балаларга тәрбия һәм белем бирү сораулары буенча мәгълүмати белешмә хезмәте; СМИ да чыгышлар; мәгълүмати кәрзиннәр, хатлар; күрсәтмә психо-педагогик пропаганда һ.б.

2. Оештыру эшләре – ата-аналар җыелышы; анкеталар тутыру; җәмгыяти ата- аналар оешмаларын төзү; коференцияләр, ата-аналар белән берлектә педсоветлар; брифинглар һ.б.

3.Культура-агарту чаралары – ата-аналар мәктәбе; консультацияләр; тематик очрашулар; матур әдәбият буенча тематик күргәзмәләр оештыру; тренинглар; семинарлар; әңгәмә; дискуссияләр; ата-аналар кунакханәсе; түгәрәк өстәл һ.б.

4.Оештыру-эшчәнлек – ата-аналар белән берлектә үткәрелгән балаларның үсеш мониторингы, берләштерелгән ата-ана-бала проекты; күргәзмәләр; вернисажлар; мастерклասслар; балалар, педагоглар, ата-аналар иҗаты; гаилә портфолиосы ясау; иҗади эшчәнлек өчен табигый һәм ташландык материаллар җыю; балалар бакчасын ремонтлауда һәм яшелләндерүдә катнашу; балаларның бакчадагы тормышын сурәтләгән буклет, видеофильмнар хәзерләү, журналлар чыгару; бакчада үткәрелгән чаралар турында фотоматериалларны электрон җибәрүдәбулышу; үстерешле предметлы тирәлекнең сыйфатын тикшерүдә катнашу һ.б.

5. Ата-аналарның педагогик процесста катнашуы – ата-аналар катнашы белән шөгыльләр; балаларга әкиятләр уку; балалар белән төрле темага әңгәмәләр кору; ата-аналар катнашы белән сәхнәләштерү; саф һавада йөргәндә, экскурсияләргә барган балаларны озату; Ачык ишекләр, Сәламәтлек көнендә катнашу һ.б.

**План работы с родителями.**

**Ата – аналар белән эшнең еллык планы 2022- 2023 уку елы**

**Сентябрь**

| № | **Эш төре** | **Күрсәтмә, белешмәләр** | **Максат** | **Җаваплылар** |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Әти – әниләр белән берлектәяңа уку елына әзерлек. | «Көндәлек режим», «Яңа уку елына бурычлар», «Без ничек яшибез», «Шкафта нәрсә булырга тиеш», «Шөгыльләр челтәре», «Без ничек үсәбез» | Яңа уку елында әти – әниләрне төркем эшендә актив катнашырга өндәү. | Тәрбиячеләр. |
| 2. | Әңгәмә «Баланың портфолиосы» | Портфолио үрнәкләре | Әти – әниләргә файдалы булган портфолио төзергәкиңәш итү. | Әти – әниләр, тәрбиячеләр. |
| 3. | Рәсем күргәзмәсе «Мин спортны яратам» | «Сәламәт тәндә – сәламәт акыл» | Сәламәт яшәү рәвеше алыпбаруга теләк тәрбияләү. | Әти – әниләр, тәрбиячеләр. |
| 4. | «Уйнап үткәнҗәй» рәсем күргәзмәсе. | Күргәзмә, бизәлеш. | Җәй турында күңелле хәтирәләр б/н уртаклашу,күңелле ял урыннарын тәкъдим итү. | Әти – әниләр, тәрбиячеләр,б алалар. |
| 5. | Ярминкә «Көзгебайлык» | «Алтын көз», ярминкәгәчакыру, күргәзмә,белдерүлә р. | Әти – әниләр б/н бергәләп көзге уңышны әзерләү, бизәү. Әти – әниләрне бакчаэшенә тарту. | Әти – әниләр, тәрбиячеләр, бакча җитәкчелеге. |

**Октябрь**

| № | **Эш төре** | **Күрсәтмә, белешмәләр** | **Максат** | **Җавап-лылар** |
|---|---|---|---|---|

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Әти – әниләр җыелышы. «Тәрбия үзенчәлекләре. Яңа уку елына әзерлек, бурычлар, чыгышлар.» | «Бергәләп өйрәник», «Без үсәбез», «Балаларның иминлеге», «Гаиләнең һәм бакчаның балаларның сәламәтлеген формалаштырудагы роле», анкеталар. | Әти – әниләрне яңа уку елы белән таныштыру, шөгыльләргә, күңел ачу чараларына тарту. Узган елгыэшкә фикер алышу һәм тәкъдимнәр кертү. | Тәрбиячеләр. |
| 2. | Күргәзмә «Минем ягымлы әбием» | Рәсем күргәзмәсе, бизәлеш. | Өлкәннәргә хөрмәттәрбияләү. | Әти – әниләр, тәрбиячеләр. |
| 3. | Күргәзмә «Татар халык ашлары» | Татар халык ашларының рәсемнәре буенча төзелгән альбомнар, фотографияләр. | Тозлы камырның үзенчәлекләре б/н таныштыру, аңлату. Татар халык ашларына кызыксынууяту. | Әти – әниләр, тәрбиячеләр. |
| 4. | Яхшы эшләр көне «Безнең канатлы дусларыбыз» | «Җимлекләр Һәм анынычек ясарга» | Әти – әниләрне балаларга әхлак тәрбиясе, бердәм хезмәткә өйрәтүгә тарту, балалар һәм өлкәннәрнең берколлективка<br><br>туплануына ирешү. | Әти – әниләр, тәрбиячеләр. |

**Ноябрь**

| № | **Эш төре** | **Күрсәтмә, белешмәләр** | **Максат** | **Җавап-лылар** |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Әңгәмә «Яхшылыкбелән тәрбиялибез», «Әхлак төбе – матургадәт», әти-әниләр киңәшмәсе «Чәй эчәбез бал белән» | Гаилә фотографияләре, альбомнар. «Елмайганда көн кояшлы», «Гафу итә белү үзе бер талант».Анкета «Ягымлы сүзләр». | Әти-әниләрне аралашуның иң яхшы алымнары б/н танышытыру. Җәза бирү һәм мактауны дөрес урында куллану. Гаиләдәге проблемаларны бергәләп чишү һәм әти-әниләргә өйдә ярдәм итү. | Әти – әниләр, тәрбияче-ләр. |
| 2. | Сәламәт булыйм дисәң «Сәламәтлек бәйрәме». | Чакыру. Папкалар «Безнең гадәтләр», «Сәламәт гаилә», «Безничек чыныгабыз», «Сәламәт тәндә –сәламәт акыл». | Гаиләләрне сәламәт яшәү рәвешенә тарту. Бердәм эш аша үзеңнең сәламәтлегеңә хөрмәт тәрбияләү. Физик културага кызыксыну уяту.. | Әти – әниләр, тәрбияче- ләр, физкультура җитәкчесе. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 3. | Рәсем күргәзмәсе «Иң матурыминем әни».Күмәк бәйрәм «Бәйрәмеңбелән ,әнием!» | Күргәзмә, «Бәйрәм белән, әниләр!», гаиләальбомнары. | Балаларга рәсем ясауда булышлык итүләрен сорау. Әниләрдә бәйрәмнәрне бергәләп үткәрү теләге уяту, бердәмлелек тәрбияләү. | Әти – әниләр, тәрбияче-ләр, музыкант. |
| 4 | Юллар имин булсын! (Әңгәмә, передвижка) | Әңгәмә, передвижка «Яшел, сары,кызыл», киңәшләр. | Балаларның иминлеген саклауда әти-әниләргә ярдәмитү. | Әти – әниләр, тәрбияче-ләр. |

**Декабрь**

| № | Эш төре | Күрсәтмә, белешмәләр | Максат | Җавап-лылар |
|---|---|---|---|---|
| 1. | «Ялыбызны файдалыуздырыйк» | «Тәрбия серләре», «Өйдә уйныйбыз», «Балаларның ялын дөрес оештырыйк», гаилә альбомнары. | Бала тәрбияләүдәге тәҗрибәләре белән уртаклашу.Әти-әни беләнбаланы якынайту. | Әти – әниләр, тәрбияче-ләр,бала-лар. |
| 2. | Әти-әниләр белән кардан сыннар, тауясау. | Сыннар, уенчыклар,р ә с е м н ә р , р ә х м ә т белдерү. | Актив эшкә катнашыргачакыру, күмәк хезмәткәөндәү. | Әти – әниләр, тәрбияче-ләр. |
| 3. | «Иң матур чыршы уенчыгы» конкурс. | Белдерү. | Балалар белән әти-әниләрнебердәмлеккә тарту, эстетик тәрбия бирү | Әти – әниләр, тәрбиячелә р,балалар. |
| 4. | Күмәк бәйрәм «Исәнме, Яңа ел!» | «Килеп җитте кыш», «Яңа ел белән!» | Бәйрәмнәрне бергә үткәрү теләге уяту, төркемне бизәүдә катнаштыру.Яңа ел костюмнары әзерләү, бәйрәмшигырьләрен өйрәнүдә булышлык итү. | Әти – әниләр, тәрбияче-ләр,бала-лар. |

**Январь**

| № | Эш төре | Күрсәтмә, белешмәләр | Максат | Җавап-лылар |
|---|---|---|---|---|

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Әңгәмә «С/р уеннарның бала үсешендәге роле» | Картотека «С/р уеннар», папка – ширма «С\р уеннар» | Әти-әниләрне уеннарның төрлелеге белән таныштыру, с/р уеннар турында мәгълүмат бирү. | Әти – әниләр, тәрбияче-ләр. |
| 2. | Кечкенә көрәкләр ясату. | Киңәшләр | Балалар белән әти-әниләрне бердәмлеккә тарту. | Әти – әниләр, тәрбияче-ләр. |
| 3. | Анкета уздыру «Гаиләдә бала» | Анкеталар | Әти-әниләрнең балаларга карата игътибарлылыгын арттыру, балаларда мөстәкыйльлекне үстерүдә ярдәм итү. | Әти – әниләр, тәрбияче-ләр,бала-лар. |
| 4 | Әти – әниләр җыелышы «Бала хокуклары» | Чакыру. Хокук тәрбиясе бирү буенча уеннар, белешмәләр, чыгышлар. | Бала хокуклары б/н тирәнтен таныштыру. | Әти – әниләр, тәрбияче-ләр. |

**Февраль**

| № | **Эш төре** | **Күрсәтмә, белешмәләр** | **Максат** | **Җавап-лылар** |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Әтиләр белән бергәләп спецмашиналар ясау. | Рәсемнәр, плакатлар, киңәшләр. Әңгәмәләр. | Әтиләрне бала тәрбияләүгә катнаштыру. бакча эшләрендә катнашырга өндәү. Балалар белән әти-әниләрне бердәмлеккә тарту. | Әти – әниләр, тәрбияче-ләр,бала-лар. |
| 2. | Әтиләр белән берлектә спорт бәйрәме | Чакырулар. Папка-ширмалар. Бүлмәнебизәү. | Әтиләрне сәламәт яшәү рәвешенә өндәү. Ял итә белү күнекмәләрен үстерү. Әтиләрне бал-ның булганлыгы б/н кызыксындыру. | Әти – әниләр, тәрбияче-ләр. |
| 3. | Слайд – шоу «Минем әтием» | Ватанны саклаучылар көненә котлаулар .Балалар кулы б\н бүләкләр ясау. | Әтиләрне бал-ның булганлыгы б/н кундыру. | Әти – әниләр, тәрбияче-ләр,бала-лар. |
| 4. | Рәсем күргәзмәсе «Минем әтием – солдат!» | Күргәзмә, «Бәйрәм белән, Әтиләр!» ,әңгәмәләр. | Балаларга рәсем ясауда булышлык итүләрен сорау. Әтиләрдә бәйрәмнәрне бергәләп үткәрү теләге уяту, бердәмлелек тәрбияләү. | Әти – әниләр, тәрбияче-ләр, балалар. |

**Март**

| № | Эш төре | Күрсәтмә, белешмәләр | Максат | Җавап-лылар |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Слайд – шоу Іинем әнием» | Балалар кулы б\нбүләкләр ясау. | Әниләрне бал-ның булганлыгы б/н куандыру. | Әти – әниләр, тәрбияче-ләр,бала-лар. |
| 2. | Бәйрәм иртәсе «Иң яхшысы минем әни» | Чакыру. Котлаушир масы. Күңеллебәйрәм иртәсе үткәрү. Төркемне бизәү. | Бәйрәмнәрне бергә үткәрү теләге уяту, төркемне бизәүдәкатнаштыру. Бәйрәмгә костюмнар әзерләү, бәйрәм шигырьләрен өйрәнүдә булышлык итү. | Әти – әниләр, тәрбияче-ләр. |
| 3. | Күргәзмә «Әниләр белән бергәләп ясыйбыз» | Киңәшләр. | Әниләрне бала тәрбияләүдә ышанычларын арттыру, бергәләп эшләргә чакыру. | Әти – әниләр, тәрбияче-ләр,бала-лар. |
| 4 | Әңгәмә | «Түземлек – әти-әнинең төп кораллы» | Балаларның тупаслыгына тупаслык б/н җавап бирергә ярамаганлыгын аңлату. | Әти – әниләр, тәрбияче-ләр. |

**Апрель**

| № | Эш төре | Күрсәтмә, белешмәләр | Максат | Җавап-лылар |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Әңгәмә «Тешләрне кариестан ничек сакларга» | Папка-ширмалар, әңгәмәләр. | Әти-әниләрне кариесның беренче билгеләре б/н таныштырө. | Әти – әниләр, тәрбияче-ләр,бала-лар. |
| 2. | Г.Тукай әкиятләренә кунака. Күргәзмә «Тукай әкиятләре» | Рәсемнәр, дәресләр, альбомнар. | Г. Тукай шигырльәренә кызыксыну, мәхәббәт уяту,әти-әниләрнең балалар б/нрәсемләү алымнаорын ныгыту. | Әти – әниләр, тәрбияче-ләр, балалар. |
| 3. | Төркемдәге уен почмакларын яңарту. | Киңәшләр. | Актив эшкә катнашырга чакыру, күмәк хезмәткәөндәү. | Әти – әниләр, тәрбиячелә |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 4. | Әти – әниләр җыелышы «Балачакни өчен кирәк?» | Анкета «Балам дөрес сөйләшәме?» Папка-ширмалар « Балагыз тотлыкса» | Әти-әниләрне балачакның әһәмияте б/н таныштыру.Бала үсешенең үзенчәлекләре турында фикер алышу. | Әти – әниләр, тәрбияче-ләр,бала-лар. |

**Май**

| № | **Эш төре** | **Күрсәтмә, белешмәләр** | **Максат** | **Җавап-лылар** |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Җиңү көненә багышланган парадта катнашу. | Папка – ширмалар. | Бәйрәмнәрне бергә үткәрү теләге уяту,бердәмлеккә тарту. | Әти – әниләр, тәрбияче-ләр, бала-лар. |
| 2. | Бакча территориясен яшелләндерү һәм төзекләндерүдә катнашу. | Әңгәмәләр «Чәчәк түтәлләре», «Безнеңя шь дуслар», «Бакчабызның яшел почмагы» | Әти-әниләрне төркем һәм участокны җәйге чорга әзерләү эшенә катнашырга чакыру. | Әти – әниләр, тәрбияче-ләр. |
| 3. | Бакчаның йомгаклау концертында катнашу. | Киңәшләр, чакырулар, әңгәмәләр. | Балалар белән әти-әниләрне бердәмлеккә тарту, эстетик тәрбия бирү | Әти – әниләр, тәрбияче-ләр, бала-лар. |
| 3. | Сабантуй бәйрәме. | Чакыру, әңгәмәләр. | Балалар белән әти-әниләрне бердәмлеккә тарту, эстетик тәрбия бирү | Әти – әниләр, тәрбияче-ләр, бала-лар. |

**Төркем бүлмәсе:**

- практик эшчәнлек өчен яракланган балалар җиһазлары;
- китап почмагы (яшь үзенчәлекләренә яракланган китаплар, экиятләргә иллюстрацияләр, пазл уеннары "Әкиятне җый", "Әкиятне танып әйт" уены, язучылар портретлары);
- тасвирлау эшчәнлеге өчен почмак (кәгазьләр, карандашлар, пластилин, балчык, кайчылар, трафаретлар, мөһерләр, калыплар, буяулар, гуашь, балавыз акбурлары, пумалалар, бизәү үрнәкләре, тозлы камыр, яраксыз материаллар, сәнгать жанрларының үрнәкләре рәсемнәре һ.б.;
- уен җиһазлары, с/р уеннар ( "Гаилә", "Шифаханә", "Төзелеш", "Уенчыклар кибете","Балалар бакчасы"," Гараж", "Төзүчеләр", "Чәчтараш","Театр").
- театр эшчәнлеге почмагы (театр төрләре папкасы; "Әкиятне танып әйт" д/у, өстәл, баркмак, шәүләле, кул һ.б театрлар);
- музыкаль эшчәнлек почмагы (курай, шөлдерле барабан, барабан, гармун һ.б. музыкаль кораллар, күргәзмә материаллар, дидактик уеннар, композиторлар портретлары, д/у);

- табигать почмагы (яшелчә, җимеш , гөмбә муляжлары, күргәзмә материаллар, дидактик уеннар, һ.б., хезмәт почмагы: алъяпкычлар, лейкалар, кечкенә көрәкләр, тырмалар);

- конструкцияләү почмагы (төрле төрдәге конструкторлар: “Лего”, “Зур шакмаклар”)

- кул-бармак эшчәнлеге почмагы (шнуровка, массаж туплары, “Энә белән муенса җыябыз” өстәл уеннары; лабиринтлар һ.б)

- өстәл, дидиактик, үстерүле уеннар почмагы;

-бизиборд;

- кызыклы математика почмагы

- туган тел почмагы (Г.Тукай портреты, аның әсәрләре җыентыгы, әсәрләр буенча ясалган д/у, татар халкының кул эше үрнәкләре, татар халкының милли әкиятләре һ.б.);- сд-проигрыватель, сд язмалар (әкиятләр, җырлар, бию көйләре, кул-бармак моторикасы гимнастикасы язмалары һ.б)

**Киенү - чишенү бүлмәсе.**

- физкультура почмагы (яшь үзенчәлекләренә яраклнган материал: х/у маскалар, туплар, кыршаулар, сикергечләр һ.б., күргәзмә папкалар, уеннар фотоархивы): - эти-әниләр өчен информацион-күргәзмә почмак(“Безнең тормыш”, “Меню”, “Котлыйбыз”, “Көндәлек режим”, “Турыдан-туры белем бирү эшчәнлегенең чөлтәре”, “Табигать үзенчәлекләре”, “Сезнең өчен эти-әниләр”, “Белдерүләр”) - сәламәтләндерү почмагы (чыныктыру һәм үз-үзеңә массаж ясау җиһазлары, массажерлар, кабыргалы такталар, пробка, төймә келәмчекләре һ.б., күргәзмә информацион материаллар.

### *III.2.Методик кулланма*

| | |
|---|---|
| **Социаль – коммуникативүсеш өлкәсе.** | Хәзрәтова, Ф. В.Туган телдә сөйләшәбез. Балалар бакчасында татар телендә тәрбия һәм белем бирү (икенче кече яшьтәгеләр төр кеме) : тәрбиячеләр өчен мето дик кулланма/Ф. В. Хәзрәтова, З. Г. Шәрәфет динова, И. Җ. Хәбибул лина.— Казан : Татар. кит. нәшр., 2012 |
| **Танып белү үсеш өлкәсе.** | “Гади математик күзаллауларны формалаштыру ”<br>И.А.Помораева,Позина В.А.-М: МОЗАЙКА-СИНТЕЗ,2017<br>Г.М.Хәкимова. Табигатькә сәяхәт (методик эшләнмә)-Яр Чаллы.<br>Ә.Х.Габдрахимова“Табигатьтә кунакта” Балалар бакчалары тәрбиячеләре өчен методик кулланма.-Яр Чаллы,2013.<br>Николаева С.Н. Юный эколог. Программа экологического воспитания в детском саду М.: Мозаика-Синтез, 2010.<br>Серия «Мир в картинках». Наглядно-дидактическое пособие. - М. Мозаика-Синтез, 2005-2011. |
| **Сөйләм үстерү өлкәсе.** | Туган телдә сөйләшәбез. Методик әсбап<br>Авторлар: Хәзрәтова Ф.В., Шәрәфетдинова З.Г., Хәбибулина И.Җ.<br>Рецензентлар:Авторлар: Хәзрәтова Ф.В., Шәрәфетдинова З.Г., Хәбибулина И.Җ.<br>Туган телдә сөйләшәбез. *Методик әсбап.* – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2013<br>Закирова К.В., Муртазина Л.Р. «Балачак-уйнап-көлеп үсәр чак»Методик кулланма.-Казан,2012.<br>Зиннурова Ф.М. « Үз илемдә,үз телемдә»-Казан:Мәгариф,2009.<br>Закирова К.В. «Балачак аланы».Хрестоматия для воспитателей и родителей.<br>Закирова К.В. «Әй уйныйбыз, уйныйбыз…(Балалар акчасында хәрәкәтле уеннар) Методик кулланма.Казан,2013. |

| | |
|---|---|
| | Закирова К.В. «Балалар бакчасында әдәп-әхлак тәрбиясе» Методик кулланма.Казан,2013.<br>М.Ф. Кашапова «Иң гүзәл тел-туган тел» Балалар бакчасында сөйләм үстерү буенча методик кулланма.-Казан:РИЦ “Школа”,2009. .“Туган телдә сөйләшәбез: методик әсбап /Ф.В.Хәзрәтова, З.Г.Шәрәфетдинова, И.Ж.Хәбибулина.-Казан:Инновацион технологияләр үзәге.-2013.-256 б.<br>Закирова К.В. “Әхлак нигезе-матру гадәт”(Гаиләдә һәм балалар бакчасында әдәп-әхлак тәрбияләү):Методик кулланма/К.В.Закирова, Р.Ә.Кадыйрова.-Казан:Мәгариф,2004.-383б.З.М.Зарипова “Бал бабай”- Яр Чаллы,2002.<br>К.В.Закирова “ Иң матур сүз”уку китабы. Балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм эти-әниләр өчен хрестоматия.-Казан,2012. |
| **Сәнгати-эстетик үсеш өлкәсе.** | Т.С. Комарова«Занятия по изобразительной деятельности во второй младшей группе детского сада»<br>Т.С. Комарова<br>«Занятия по изобразительной деятельности во второй младшей группе детского сада»<br>Белем һәм тәрбия эшчәнлегенең перспектив программасы «туганнан мәктәпкә кадәр» Н.Е. Веракса, М.А. Васильевой, Т.С. Комаровой. К.З.Закирова «Күңел ачыйк бергәләп»-Казан. «МӘГАРИФ»НӘШРИЯТЕ.2003. |
| **Физик үсеш** | Лайзане С. Я. Физическая культура для малышей. Пособие для воспитателя дет. сада. «Просвещение», 1978.<br>К.З.Закирова «Күңел ачыйк бергәләп»-Казан. «МӘГАРИФ»НӘШРИЯТЕ.2003.<br>Виды спорта. Наглядно-дидактическое пособие. |
| **Этномәдәни төбәк бердәмлеге** | Зарипова З.М. « Туган телдә сөйләшәбез» 2-3 яшь. Методик кулланма.-Казан: «Фолиант», 2012.<br>Закирова К.В., Кадырова Р.Э. «Әхлак нигезе-матур гадәт»-«Мәгариф»,2004.<br>Закирова К.В., Муртазина Л.Р. «Балачак-уйнап-көлеп үсәр чак»Методик кулланма.-Казан,2012.<br>Зиннурова Ф.М. « Үзилемдә,үз телемдә»-Казан:Мәгариф,2009.<br>Закирова К.В. «Балачак аланы». Хрестоматия для воспитателей и родителей.<br>ЗакироваК.В.«Әй уйныйбыз, уйныйбыз. (Балалар бакчасында хәрәкәтле уеннар) Методик кулланма.Казан,2013.<br>Закирова К.В. «Балалар бакчасында әдәп-әхлак тәрбиясе» Туган телдә сөйләшәбез.Методик кулланма өчен аудио-кушымта:<br>Диск “Балалар бакчасында әдәп- әхлак тәрбиясе”Методик әсбап өчен аудио-кушымта<br>Аудио – китап “Татар әкиятләре”<br>«Танцы народов Поволжья» (аудиодиски).<br>«Татар әкиятләре»-музыкальные сказки на татарском языке. |

### *III.3.Үстерешле предметлы тирәлекнең үзенчәлекләре.*

1.Үстерешле предметлы тирәлек балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып, аларның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту өчен төркемдә һәм балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү процессын максималь тормышка ашыра.

2. Үстерешле предметлы тирәлек балалар белән өлкәннәрнең аралашу мөмкинлеге, бердәм эшчәнлеге,балаларның хәрәкәт активлыгы, шулай ук аларның ялгыз калу мөмкинлеге белән тәэмин итә.
3. Үстерешле предметлы тирәлек:
- төрле тәрбия һәм белем бирү программаларын тормышка ашыруны;
- милли культура, климат шартларын;
- балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алырга тиеш.
4.Үстерешле предметлы тирәлек бай эчтәлекле, үзгәрүчән, күпфункцияле, вариатив, аңлаешлы һәм куркынычсыз булырга тиеш.Предметлы тирәлек белән тулыландыру тәрбия һәм белем бирү процессының бербөтенлек принципына,ФДББС буенча балаларның психологик һәм шәхси үзенчәлекләренә, материалларның үзенә хас үзгәрүчән уеннар, дидактик материаллар белән тәэмин ителүенә, балалар белән өлкәннәрнең интегральләштерү принципына, балаларның уен, хәрәкәт активлыгы, эзләнү, тәҗрибә, конструктив, матур әдәбиятны кабул итү һәм коммуникатив эшчәнлегенә туры килә. Милли культура, климат шартлары исәпкә алына. Кулланылган материалларның һәм җиһазларның сыйфат сертификатлары бар һәм алар гигиена, педагогик, эстетик таләпләргә җавап бирә алалар.

### *III.4. Көндәлек режим*

Көндәлек режим ул- балаларның эшчәнлек төрләре һәм ялының рациональ дәвамлылыгы, дөрес чиратлашуы. Режим моментлары түбәндәгеләрне истә тотып төзелде:

- балаларның төркемдә булу вакытлары;
- гамәлдәге санитария нормалары һәм кагыйдәләре(Сан Пин);
- мәктәпкәчә белем бирү өлкәсендә федераль дәүләт таләпләре;
- белем бирү процессын тормышка ашыруның үзенчәлекле шартлары (климатик, милли-мәдәни һ.б.);
- ел фасыллары.

Программаны үзләштерү, тормышка ашыру буенча өлкәннәр һәм балалар эшчәнлеге көндәлек режимда ике төп модельдә оештырыла: өлкәннәр һәм балаларның уртак эшчәнлеге, балаларның мөстәкыль эшчәнлеге.

| | |
|---|---|
| Балаларны кабул итү, карау, ирекле уен | 6.00-6.30 |
| Балаларны кабул итү, карау, ирекле уен | 6.30 -8.00 |
| Иртәнге гимнастика | 8.00- 8.10 |
| Уеннар,мөстәкыйль эш | 8.10-8.20 |
| Иртәнге ашка әзерлек, иртәнге аш | 8.20-8.40 |
| Белем бирү эшчәнлегенә әзерлек, Уеннар,мөстәкыйль эш) | 8.40- 9.00 |
| Оештырылган белем бирү эшчәнлеге (тәнәфесләрне кертеп | 9.00- 9.40 |
| Уен эшчәнлеге | 9.40 – 10.00 |
| Уен эшчәнлеге | 10.00-10.10 |
| Йөрүгә әзерлек, йөрү | 10.10-11.40 |
| Йөрүдән кайту, уеннар, төшке ашка әзерлек | 11.40 -12.00 |
| Төшке аш | 12.00-12.20 |
| Көндезге йокыга әзерлек, көндезге йокы | 12.20-15.00 |
| Акрынлап йокыдан тору, һава һәм су процедуралары, йокыдан соң гимнастика | 15.00-15.15 |
| Төшлек ашка әзерлек, төшлек | 15.15-15.30 |

| | |
|---|---|
| Белем бирү эшчәнлеге, уеннар – дәресләр, динамик паузалар, нәфис әдәбият уку, түгәрәкләр | 15.30- 15.50 |
| Вечерний круг | 15.50-16.05 |
| Йөрүгә әзерлек | 16.10- 16.15 |
| Йөрү,урамда уеннар, балаларның мөстәкыйль эшчәнлеге, балаларның өйләренә китүе | 16.15-18.00 |

***III.5. Белем бирү эшчәнлеге челтәре***

| | |
|---|---|
| Дүшәмбе | **9.00-9.15 Музыка**<br>**Музыкальное**<br>**9.25-9..40 Танып белү өлкәсе: әйләнә-тирә күзаллауны формалаштыру**<br>**Познание (Ознакомление с окр)** |
| Сишәмбе | **9.00-9.15 Танып белү өлкәсе: элементар математик күзаллауны**<br>**Познание (ФЭМП)**<br>**9.20-9.30 Физик культура**<br>**Физкультурное** |
| Чәршәмбе | **9.00-9.15 Музыка**<br>**Музыкальное**<br>**9.25- 9.40 Сөйләм үсеше/Матур әдәбият уку**<br>Развитие речи |
| Пәнҗешәмбе | **9.00-9.15 Әвәләү / кисеп ябыштыру/ кул эше**<br>**Лепка/ Аппликация/ Ручной труд**<br>**9.25-9.40 Физик культура**<br>**Физкультурное** |
| Җомга | **9.00- 9.15 Рәсем**<br>**Рисование**<br>**9.25-9.40 Физик культура һавада**<br>**Физкультура на воздухе** |

### *III.6.Сәламәтләндерү чаралары*

1.Иртәнге гимнастика.
2. Саф һавада уеннар
3. Физкультминутлар уздыру
4. Оксалин мазе белән борыннарга сөртү
5.Фитонцидлар белән төркемне исләндерү.
6. Поливитаминнар.
7. Чыныктыру чаралары.
8.Йокыдан соңгы гимнастика.

### *III.7.Традицион вакыйгалар, бәйрәмнәр, чаралар.*

Оештырылган комплекслы-тематик принцибын гамәлгә ашыруда үрнәк темалар тора (бәйрәмнәр, вакыйгалар, проектлар),балаларның барлык үсешенә юнәлгән һәм төрле

яклап кеше яшәешенә багышланган,шулай ук балаларның шәхсән кызыксынуларын тудыра:

• баланың әхлакый тормыш күренешендә әйләнә-тирә табигатьтә
• сәнгать һәм әдәбият дөньясында
• гадәти гаилә өчен, җәмгыять һәм дәүләтнең бәйрәм вакыйгаларына
• гражданлык хисе формулаштыруда балага кирәкле тирәлек (туган шәһәр.)

Балалар бакчасында үткәрелә торган чаралар:

- «Көз», “Сөмбелә” 8 март, Яңа ел, «Саумы,җәй!»
- Әниләр көненә багышланган концерт.
- «Масленица»
-“Нәүрүз”
- «Чыршы белән саубуллашу»
- Халыкара телләр көне
- « Нептун бәйрәме»
- «Сабантуй»

## *Кулланылган әдәбият исемлеге:*

1. Хәзрәтова, Ф. В.Туган телдә сөйләшәбез. Балалар бакчасында татар телендә тәрбия һәм белем бирү (беренче кече яшь тәгеләр төр кеме) : тәрбиячеләр өчен мето дик кулланма/Ф. В. Хәзрәтова, З. Г. Шәрәфет динова, И. Җ. Хәби бул лина.— Казан : Татар. кит. нәшр., 2012.— 191 б.

2. Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү программасы / төз.: К. В. Закирова, Р. А. Борһанова. — Казан : Хәтер, 2000.

3. Гөлбакча : балалар бакчалары өчен хрестоматия : балалар бакчаларында эшләүче тәрбиячеләр өчен кулланма. — Казан : Та-тар. кит. нәшр., 1990.

4. Гөлбостан : балалар бакчасында телләр үстерү өчен методик кулланма / Ф. Г. Агнабаева, Г. Р. Елкыбаева, А. З. Нарынбаева, М. Р. Харисова, Р. И. Әминева. — Өфе : Китап, 2010. — 416 б.

5. От рождения до школы : примерная основная общеобразо-вательная программа дошкольного образования / под ред. Н. Е. Вераксы, Т. С. Комаровой, М. А. Васильевой. — М.: Мозаика-Синтез, 2010. — 304 с.

6. Раушан көзге : татар балалар әдәбиятыннан хрестоматия : педагогия училищеларының мәктәпкәчә яшьтәге балаларны тәрбияләү бүлеге өчен кулланма. — Казан : Мәгариф, 1993. — 255 б.

7. Игралочка ., Петерсон Л.Г, Кочемасова Е.Е, Просвещение/ бином 2021 г.в

8. Д.Н. Колдина Лепка и рисование с детьми 3-4 лет. Конспекты занятий. – М.: Мозайка- синтез, 2007.-056 с.

9. Занятия по ИЗО, Т.С. Комарова, Москва 2011 г.в.

10. Л.И. Пензулаева «Физкультурные занятия в детском саду» вторая младшая групп М.:- Мозайка-синтез, 2012

11. Куцакова Л.В. Конструирование и ручной труд в детском саду: пособие для воспитателейдетского сада. – М.: Просвещение, 1990.

12. Е.В. Колесникова, Рабочая тетрадь развитие речи, Москва, 2010 г.в.